| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**05.02.2018 ел** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 232** |

Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 27 мартындагы 31 номерлы карары белән расланган «2029 елга кадәр Зеленодольск муниципаль районы Зеленодольск шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасы» проектына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Җылылык белән тәэмин итү турында» 190-ФЗ номерлы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»131-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 февралендәге «Җылылык белән тәэмин итү схемаларына, аларны эшләү һәм раслау тәртибенә таләпләр турында» 154 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 27 мартындагы 31 номерлы карары белән расланган «Зеленодольск муниципаль районы шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасы» проектына түбәндәге өстәмәләр кертергә: 5 бүлек 5.8.1 пункт, 5.8.2 пункт «Җылылык энергиясе чыганакларын төзү, реконструкцияләү һәм техник яктан яңадан җиһазлау буенча тәкъдимнәр» , 9 бүлек 9.1 пункт «Төзелешкә, реконструкцияләүгә һәм техник яктан яңадан кораллandыруга инвестицияләрне нигезләү» .
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигы Д.С.Анисимовка әлеге карар кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә аны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында урнаштырырга (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 05 февралендәге
232 номерлы карарына
кушымта

1. 5 бүлек ,5.8.1пункт :

- Б.Урманче урамындагы КРТП-7 эксплуатациядән чыгару һәм 2, 3, 3а, 10, 12, 14, 16 нчы торак йортларны ике торбалы җылылык белән тәэмин итү системасына күчерү һәм йортларның подвалында ИТП урнаштыру күздә тотыла.

КРТП-7 җиһазларын эксплуатациядән чыгаруның төп сәбәпләре түбәндәгеләр:

- КРТП-7 төп җиһазларының тузуы;
- торак йортларга кайнар су белән тәэмин итү челтәрләренең тузуы;
- торак йортларда кайнар су белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту.

2. 5 бүлек, 5.8.2 пункт :

- Почта урамындагы 3 нче йортка җылылык челтәрен эксплуатациядән чыгару һәм фатирларны электр казаннарына күчерү күздә тотыла.

Җылылык челтәрен эксплуатациядән чыгаруның төп сәбәпләре түбәндәгеләр:

- Почтовая урамы буенча 2 нче фатирлы 3 нче йортка җылылык челтәренең озынлыгы зур булу һәм тузуы;
- торак йортта җылылык белән тәэмин итүнең сыйфатын яхшырту.

3. 9 бүлек, 9.1 пункт :

- Б.Урманче урамындагы КРТП-7 эксплуатациядән чыгару һәм 2, 3, 3а, 10, 12, 14, 16 нчы торак йортларны ике торбалы җылылык белән тәэмин итү системасына күчерү һәм йортларның подвалында ИТП урнаштыру. Реконструкциягә чыгымнар 12,7 млн. сум тәшкил итә.
- Почтовая урамындагы 3 нче торак йортка фатирларны электр казаннарына күчереп җылылык челтәрен эксплуатацияләүдән чыгару. Реконструкциягә чыгымнар 300,0 мең сум тәшкил итә.